**СОВЕТ**
**НОВОШЕШМИНСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯҢА ЧИШМӘ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2024 елның «23» маеннан №46-347

Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә инвалидларны эшкә урнаштыру өчен эш урыннарын квоталау һәм резервлау мәсьәләләре өлешендә инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен эш урыннарын квоталау һәм резервлау турында мәгълүмат

«Яңа Чишмә районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ директоры Р.Г. Хөснуллинаның Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә инвалидларны эшкә урнаштыру өчен эш урыннарын квоталау һәм резервлау мәсьәләләре өлешендә инвалидлар һәм социаль яклауга аеручa мохтаҗ гражданнар өчен эш урыннарын квоталау һәм резервлау турында мәгълүматын тыңлаганнан соң, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. «Яңа Чишмә районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ директоры Р.Г. Хөснуллинаның Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә инвалидларны эшкә урнаштыру өчен эш урыннарын квоталау һәм резервлау мәсьәләләре өлешендә инвалидлар һәм социаль яклауга аеручa мохтаҗ гражданнар өчен эш урыннарын квоталау һәм резервлау турында мәгълүматын игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы учреждениеләре һәм оешмаларына «Яңа Чишмә районы халкын эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесенә инвалидлар өчен эш урыннарын квоталаганда һәм резервлаганда ярдәм күрсәтергә.

3. «Яңа Чишмә районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ директорына түбәндәге эшләрне башкарырга:

инвалидлар өчен эш урыннарын квоталау һәм резервлау буенча эшне дәвам итәргә;

- инвалидларны эшкә урнаштырганда мөмкин булган каршылыкларны бәяләргә, аларны бетерү чараларын күрергә һәм инвалидларны тулы булмаган эш урыннары һәм (яисә) эш белән тәэмин итүнең үзгәрүчән формалары булган эш урыннарына эшкә урнаштыру мөмкинлеген киңәйтергә;

- инвалидларны, шул исәптән мәгариф учреждениеләрен тәмамлаучыларны эшкә урнаштыру, эш урыннарына яраклаштыру һәм беркетү максатларында эшкә урнаштырганда үз эшчәнлеген гамәлгә ашыручы социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалар белән хезмәттәшлекне дәвам итәргә.

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында https://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының социаль, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы В. М. Козлов